2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип тимер юл станциясе Урман- Кәләй авыл җирлеге гражданнарының үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫКАРАРЫ

11 ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип тимер юл станциясеУрман- Кәләй авыл җирлеге гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип тимер юл станциясе Урман- Кәләй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 3500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: Колшәрип тимер юл станциясе бистәсен яшәү урыны җирлек территориясендә булган һәр балигъ яшьтәге гражданинын су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү, насос бинасын тезекләндерү,смета төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү , җирлек милкенә рәсмиләштерү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Колшәрип тимер юл станциясе Железнодорожная урамы 10 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендәӘлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Урман- Кәләй авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Фәләхиев